**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Глава
Микулинского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района**

423306, Азнакаевский район,
с. Микулино, ул. Советская, д.74
тел.8(855-92)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге
Советы
Башлыгы**

423306, Азнакай районы,
Микулино авылы, Совет урамы, 74
тел.8(855-92)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

« 15» ноябрь 2021 ел — №7

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Дмитриевка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәлә себуенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федеральзаконның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Микулино авылҗирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Дмитриевка авылында сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 2 декабрендә 15 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Дмитриевка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыен уздыру вакыты – 2 декабрь 2021 ел 15.00 сәг.тән 16.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенын үткәрү урыны – Дмитриевка авылы.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдими тәргә:

- 2021 елның 22 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Дмитриевка авылы.

- Дмитриевка торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- массакүләммәгълүматчараларында һәм башка ысуллар белән Дмитриевка торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәритәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләнерасларга:

«Сез 2022 елда Микулино авыл җирлеге Дмитриевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашу чылардан, Бөек Ватан сугышынд катнашу чыларның тол хатыннарыннан, көндезгеуку формасында укучы студентлардантыш, 300 сумкүләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кыш көне юлларны кардан чистарту;

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Микулин авылы, Совет ур., 74 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: И.А.Такиулин